ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**30.12.2022ел**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 3629**

Зеленодольск шәһәренең Башкала урамы
буенча транспорт чаралары хәрәкәтен
туктату һәм юл хәрәкәте иминлеген тәэмин
итү максатларында

Юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү максатларында, Зеленодольск муниципаль районының юл хәрәкәте иминлеге комиссиясенең 2022 елның 08 августындагы 01-03-09-03 номерлы карары нигезендә, «Юл хәрәкәте иминлеге турында» 1995 елның 10 декабрендәге 196-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясына, «Россия Федерациясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында»» 2007 елның 08 ноябрендәге 257-ФЗ номерлы Федераль законның 30 статьясына таянып , Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1.2022 елның 30 декабреннән Зеленодольск шәһәренең Башкала урамы 2а номерлы йорт яны буенча транспорт чаралары хәрәкәтен туктатырга.

2. Ашыгыч хезмәтләргә оператив керү мөмкинлеген тәэмин итү максатыннан, 6.8.1 «Тупик» юл билгеләрен һәм «Борылыш шлагбаумы» тибындагы барьер киртәләрен кую.

3. «ЗМР төзелеш һәм инфраструктура үсеше департаменты» МБУ житәкчесе урынбасарына Зеленодольск шәһәренең Башкала урамы юл хәрәкәтен оештыру проектына үзгәрешләр кертергә.

4. Зеленодольск муниципаль район Советы аппаратының җәмәгатьчелек, массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә әлеге карарны интернет челтәренең Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru ) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләр составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru ) урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче вазифаларын башкаручы А.В. Старостин